КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 710

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган аерым категорияләренә, гомуми белем бирү оешмаларының 7 яшьтән өлкәнрәк укучыларына һәм тәрбияләнүчеләренә, һөнәр белеме бирү оешмаларының һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының көндезге формада белем алучы студентларына шәһәр яны элемтәсендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты белән хезмәтләр күрсәткәндә тарифлар буенча ташламалар бирү турында» 2013 ел, 4 март, 145 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган аерым категорияләренә, гомуми белем бирү оешмаларының 7 яшьтән өлкәнрәк укучыларына һәм тәрбияләнүчеләренә, һөнәр белеме бирү оешмаларының һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының көндезге формада белем алучы студентларына шәһәр яны элемтәсендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты белән хезмәтләр күрсәткәндә тарифлар буенча ташламалар бирү турында» 2013 ел, 4 март, 145 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 26 июнь, 437 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 22 май, 430 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр яны элемтәсендә гомуми файдаланудагы тимер юл транспорты белән хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы территориясе буенча юл йөрү документын (билет) сатып алганда гамәлдәге тарифлар буенча 50 процентлы ташлама рәвешендә түбәндәгеләргә ташлама (алга таба – тарифлар буенча ташлама) билгеләргә:»;

2 пунктта:

беренче абзацка «Татарстан Республикасы территориясе чикләре кысаларында» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «, шулай ук Россия Федерациясенең башка субъектлары территорияләре буйлап сәфәр маршруты узудан» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин